КЫЙММӘТЛЕ ЖЫЛЫЛЫК

Торак-коммуналь түләүләр квитанциясе күпләрне гаҗәпкә калдырган

> 2

ЕГЕТЛӘР ЛИЦЕЕ

Гендерлы укытуның нинди тискәре һәм уңай яклары бар?

> 3

МӘР ӘНИСЕ:

«Мин язмышыма бик рәхмәтле»

> 4

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

«Ярамый» диелгән нәрсәләрне гел эшләп карыйсы килә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 150 (28923) | Чәршәмбе | 12 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Төзелеш

190 млрд сум. Быел Татарстанда юллар төзү һәм төзекләндерүгә каралган акча күләме бу. Республиканың транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов сүзләренчә, тарихта мондый хәлнең булганы юк әле. Быел юлларда башкарыла торган эшнең күләмен узган еллар белән чагыштырырлык та түгел. Нәтиҗәсен кайчан күрербез? Хөкүмәт йортында узган брифингта шул хакта сөйләделәр.

metshin.ru

ХӨЕРЛЕ БУЛСЫН ЮЛЛАР

Бу атна азагында юл хуҗалыгы хезмәткәрләре һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп узачак. Ләкин әлегә күңел ачарга вакытлары юк – юлларда эш гөрли. Быел Татарстанда юллар төзелешенә 190 млрд сумнан артык акча юнәлдерелгән. Фәрит Хәнифов сүзләренчә, мөгаен, мондый хәлнең Татарстанда гына түгел, Россиядә дә булганы юктыр әле.

– Юл төзелешенең мондый күләмдә алып барылганы юк иде. Билгеле, бу мәсьәләдә федераль заказчыларның булуы зур роль уйный, – диде ул. – Планга кертелгән объектларда тоткарлыклар юк. Араларында иң зурысы – М12 Мәскәү – Казан трассасы. Аның җиденче һәм сигезенче этабы безнең республика аша уза. Быел аларны төзүгә 101 млрд сум акча юнәлтелде.

Икенче мөһим һәм зур объект – М7 трассасы. Хәзерге вакытта анда да төзекләндерү эшләре дәвам итә. Чаллы белән Түбән Каманы урап уза торган 81,4 чакрым юл төзиләр, Чаллыдан Башкортстан чигенә кадәр юлны дүрт полосалы итеп киңәйтәләр. Министр сүзләренчә, 2024 елга М7 трассасының Татарстан аша уза торган өлеше тулысынча дүрт полосалы булачак.

Республиканың үз юлларына килгәндә, хәзерге вакытта Татарстанда 73,2 млрд сумлык юл төзелә һәм төзекләндерелә.

– Шул ук вакытта инфраструктура кредиты хисабына да эшләр алып барыла. Нәтиҗәдә башкаладагы Горький шоссесы алты полосага кадәр җиткереләчәк, Вознесение тракты төзеләчәк. Соңгы объектның беренче өлеше Гвардия урамы белән Җиңү проспектын тоташтырса, икенче өлеше Җиңү проспектыннан М7 трассасына кадәр сузылачак. Хәзерге вакытта ике өлештә дә эшләр бара. Вознесение трактында эшләрне 2025 елга тәмамларга ниятлибез. Казан өчен бик әһәмиятле, кирәкле юл ул. Шушы ук программа буенча «Салават Күпере» микрорайонына илтә торган Осиново урамы инде төзекләндерелде, бу көннәрдә без аны кулланылышка тапшырачакбыз, – дип сөйләде Фәрит Хәнифов.

Моннан тыш, республикада «Куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты кысасында да юл эшләре дәвам итә. Быел әлеге проектны тормышка ашыруга 9,78 млрд сум акча бүленгән. Министр сүзләренчә, проект кысасында каралган юл эшләре Казан, Чаллы һәм Түбән Кама кебек өч зур шәһәр агломерациясендә башкарыла. Әлеге проект кысасында күперләр ремонтлауга 1,9 млрд сумга якын акча сарыф ителәчәк. Хәзерге вакытта 21 объектта эшләр 82 процентка үтәлгән.

– Шулай ук Татарстанда юл-урам челтәрен ремонтлау буенча өч социаль программа эшли. Хәзер гомуми озынлыгы 120 чакрым булган 300 объектта эшләр башкарыла. Бу эшләргә 1,2 млрд сум акча сарыф ителәчәк. Моннан тыш, фермер хуҗалыкларына илтә торган – 12, бакчачылык ширкәтләренә илтә торган – 14, балалар лагерьларына илтә торган 6 юлны төзекләндерү буенча эшләр башкарыла, – дип аңлатты министр.

Казанда да юл эшләре туктап тормый. Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Игорь Куляжев сүзләренә караганда, быел башкаладагы юл эшләренә 25,6 млрд сум акча бүленгән.

– Шул исәптән 1 млрд сум «Куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты кысасында ремонт эшләренә тотылачак. 5,4 миллиард сум урам-юл челтәрен төзекләндерү, светофорлар, яктырту объектлары урнаштыруга сарыф ителәчәк. Калганы автомобиль юллары төзү һәм төзекләндерүгә бүленгән, – дип сөйләде ул.

12–14 октябрьдә «Казан Экспо»да «Юл – 2022» халыкара күргәзмәсе узачак. Әлеге чара кысасында Россиядә һәм, аерым алганда, Татарстанда алдагы биш елга юл-төзекләндерү эшләренең планы турында фикер алышачаклар. Шулай ук халыкара чарада импортны алыштыру мәсьәләсенә кагылышлы сөйләшүләр узачак.

САН

Өч квартал нәтиҗәләре буенча, республикада **50** чакрым юл төзелеп, **600** чакрым юл төзекләндерелгән. Бу – планның **95** проценты.

Җәмигъ мәчетенә ярдәм

Казандагы Җәмигъ мәчете төзелешенә ярдәм итәргә теләүчеләр өчен махсус сайт эшли. Игелекле эшкә үз өлешен кертергә теләгән һәркем igelek.tatar сайтына кереп, акчалата ярдәм калдыра ала. Бу хакта Татарстан Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте хәбәр итә. «Теләгән һәркем мөселманнар өчен мөһим проектка матди яктан ярдәм итә ала. Моны сайт аша да, банк реквизитлары буенча да эшләп була», – диелә хәбәрдә.

Җәмигъ мәчете төзелешенә акчалата ярдәмне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте бинасындагы иганәләр өчен тартмаларда да калдырырга мөмкин.

Түбән Камада күбрәк

Татарстанда сентябрьдә теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе 0,49 процентны тәшкил итә. Бу – 9,9 мең кеше дигән сүз. Республиканың Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, август белән чагыштырганда, әлеге күрсәткеч 0,02 процентка кимегән.

Узган айда теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе Түбән Кама (0,71%), Югары Ослан (0,68%) һәм Алабуга (0,68%) районнарында югары булган. Казан (0,62%) – дүртенче, Әгерҗе (0,60%) – бишенче. Алексеевск, Лаеш һәм Минзәлә районнарында теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе республикада иң түбәне булган.

Бәясе кими

Быел ипинең бәясе кимергә мөмкин. Бу хакта Россиянең авыл хуҗалыгы министрының беренче урынбасары Оксана Луткага сылтама белән «ТАСС» мәгълүмат агентлыгы хәбәр итә. «Хәзерге вакытта төп чималга бәяләр кими. Шуннан чыгып, ипинең дә хакы кимер дип көтәбез», – дигән министр урынбасары.

Бүген Россиядә бодай һәм арышка бәяләрнең кимүе күзәтелә. Бу илдәге быелгы уңышның мул булуы белән бәйле. Инде хәзердән үк кайбер продуктларның арзанаюы күзәтелә. Әйтик, он бәясе якынча 3 процентка кимегән.

Акча

Исемсез карта

Банк картасы исемсез буламы? Була. Әмма банк картасында хуҗасының исеме юк дип, бу аны ирекле төстә һәм теләсә кайда файдаланырга мөмкин дигән сүз түгел, ул барыбер билгеле бер финанс системасына бәйле.

Чит илләрдә санкциягә эләккән Россия банклары карталарыннан файдалану көннән-көн катлаулана бара. Хәтта соңгы вакыйгалардан соң күп илләр «Мир» картасыннан да баш тартты. Сәбәбе бер: АКШ санкцияләреннән шикләнәләр. Исемсез карталар менә шундый вакытта ярдәмгә килергә мөмкин дә инде дип саный Финанс базары буенча Дәүләт Думасы комитеты җитәкчесе Анатолий Аксаков. Мондый карталардан «Мир» картасыннан баш тарткан илләрдә дә файдаланырга була. Депутат фикеренчә, исемсез карталарны нинди дә булса аерым бер илгә бәйле булмаган, бөтен дөньяга хезмәт күрсәткән, шуңа күрә дә санкцияләргә дучар булмаган халыкара финанс системалары гамәлгә кертергә мөмкин. Сүз дә юк, бу механизмны эшләтеп җибәрү өчен вакыт кирәк, әмма нинди дә булса варианты барыбер табылачак, дип ышандыра сәясәтче.

– Аноним карталар һәм төрледән-төрле электрон кошелеклар Россиядә бүген дә киң таралган. Әмма аларның һәрберсенең үз операторы бар. Кагыйдә буларак, бу – банк. Әгәр банк Россиянеке булса, ул санкцияләргә дучар ителгән, димәк, чикләүләрдән берничек тә качып булмый, – дип үз фикерен белдерә Илкүләм түләү советы идарәсе җитәкчесе Алма Обаева.

Әгәр тегe яки бу илдә түләүләрне идентификацияли торган система булса, анда сатып алынган әйберләр өчен түләргә булыр иде, дип саный эксперт. Бүген Россия белән Төркия әнә шундый системаны булдыру өстендә эшли. Бу очракта карталарны нинди дә булса дәүләтара корпорация чыгарачак һәм ул, нинди банктан булуына карамастан, акчаны бер счеттан икенчесенә күчерәчәк. Әлбәттә инде, акча һавадан алынмый, сатучысы да, сатып алучысы да билгеле булачак.

Исемсез дебет карталарын хәзер Россия банклары да күпләп чыгара. Аларның аермасы шунда: пластикка хуҗасының фамилиясе язылмый. Мондый карталардан гадәттә үзенең кем икәнлеген белгертергә теләмәгән кешеләр файдалана. Әйтергә кирәк, мондый карталарның уңай яклары да бар. Аларны банкка мөрәҗәгать иткән көнне үк алырга мөмкин, шул ук вакытта исемлеләрне берничә көн көтәргә туры килә. Банк хезмәте өчен акча да алынмый. Әмма тискәре яклары да юк түгел. Исемсез карталарга банкоматларда акча алу өчен чикләүләр кертелә. Андагы акчаны башка кешегә күчерергә мөмкин түгел. Моннан тыш бу карталарга берничә дә дәүләт түләүләрен алып булмый. Чит илләрдә дә, әгәр операторы санкциягә дучар икән, нәкъ исемлеләре кебек исемсезләре белән дә эш йөртеп булмый.

Исемсез карталарның тагын бер төре бар. Бу – алдан түләп куелганнары. Андыйларны чит илдә сатып алырга яки онлайн рәсмиләштерергә мөмкин. «Безнең «Пушкин картасы» нәкъ шушы системада эшли, – дип аңлатма бирә Алма Обаева. – Чит илдә алдан түләп куелган карталар санкциягә дучар булмый, ягъни алардан теләсә кайда файдаланырга мөмкин. Кагыйдә буларак, билгеле бер суммада лимит бар, кайчагында комиссия түләргә туры килә. Россия туристлары да мондый карталардан файдалана башлады инде. Әмма заказ биргәндә чикләүләргә игътибар итәргә онытмаска кирәк. Кайбер карталар аерым бер илләр өчен генә яраклы. Шул ук вакытта Россиядә дә аларны куллану мөмкин түгел».

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сүзгә-сүз

Казан мэры Илсур МЕТШИН:

Бассейннармы бу, яшүсмерләр клубларымы, ниндидер өстәмә мәктәптән тыш дәресләрме һәм җәмәгать транспортымы, зинһар, сизгер мөнәсәбәт булсын, берничә бюрократия булмасын. Ирләре хезмәткә киткән гаиләләр, хатын-кызлар авыр чорны кичерә. Безнең бурыч хәзер – аларга ярдәм күрсәтү, алар белән даими элемтәдә тору. Әгәр дә без ярдәм чаралары исемлегендә нәрсәне дә булса төшереп калдырганны аңласак, һичшиксез тулыландырачакбыз.

(«Эшлекле дүшәмбе»дән)

РОССИЯДӘ – АКЧА ТОТУ

Соңгы җиде айда Россиядә акчаларын янга калдырырга тырышучылар арткан. Superjob хезмәте уздырган сораштыру нәтиҗәләре шул хакта сөйли.



46% >>	экономияләргә тырыша
28% >>	акча мәсьәләсендә берни үзгәртмәгән
9% >>	акчаны күбрәк тота башлаган
17% >>	Җавап бирергә кыенсынганнар

Көннәр бозыла

Бу атна ахырында Татарстанда һава торышы үзгәрәчәк. Республиканың Гидрометеорология үзәге мәгълүматларына караганда, ялларга һава температурасы +4 градуска кадәр төшәргә мөмкин. Синоптиклар хәбәр итүенчә, пәнҗешәмбе – 13 октябрьдә урыны белән явым-төшемнәр көтелә. Көндез һава температурасы +8…+14 градус булса, төнге сәгатьләрдә +3…+8 градусны тәшкил итәчәк. Белгечләр сүзләренчә, 14 һәм 15 октябрьдән республикада суытачак. Урыны белән явым-төшем ихтималы бар. Һава температурасы көндезге сәгатьләрдә дә +4…+9 градустан югары булмас.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 3–13 октябрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя **444 сум 54 тиен**, гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **980 сум 10 тиен**, гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Реклама 16+



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

РАКЕТА ҺӨҖҮМЕНӘ КӨНБАТЫШ ҖАВАБЫ

Кырым күперендәге теракттан соң күпсанлы ракеталар белән берьюлы Украинаның инфраструктурасына һөҗүм итү төрле илләрдә зур яңгыраш тапты. Һөҗүмнең берничә максаты бар иде: Украинаны куркытып һәм хәлсезләндереп сөйләшүләр өстәле янына утырту һәм Россия куйган шартларда килешү төзергә мәҗбүр итү, Көнбатышны Украинадан сатып ала торган электр энергиясеннән мәхрүм итү һәм андагы энергетик кризисны кискенләштерү. Соңгысы шулай ук Европа башкалаларының Киевка басымын көчәйтергә тиеш дип уйланды. Украинага ярдәм күрсәтүдән Көнбатышта алҗырлар һәм тәртәләрне кире борырга теләрләр дигән өмет тә юк түгел. Чынлап та, Европада да, океан артында да зур гына сәясәтчеләрнең Украинага каршы тавышлары ишетелми түгел, ишетелә. Америка конгрессмены Пол Госар, мәсәлән: «Без катнашырга тиеш булмаган сугышны финанслау өчен бүтән берниндн чит ил ярдәме дә булмасын. Байден һәм аның криминаль гаиләсе, бәлки, Зеленскийга бурычлыдыр, әмма Американың аңа бирәчәге юк», – дип белдерде. Әмма андый тавышлар берән-сәрән генә. Көнбатыш сәясәтчеләре күпчелектә Киевка финанс һәм хәрби ярдәмне арттыруны хуәтлиләр. Дүшәмбе һөҗүменнән соң Украинаны яңа төр технологик кораллар белән тәэмин итү көчәйде. «Российская газета»ның сайты БМОдагы Россия вәкиле Небензяның бу уңайдан ясаган чыгышыннан өзек китерә: «НАТОның максаты... Россияне җиңү яисә һич югында көчсезләндерү», – ди ул. Россиянең АКШтагы илчесе Антонов та: «АКШ хакимиятләренең Киев режимына хәрби максатлардагы өстәмә продукция белән ярдәм күрсәтү турындагы белдерүләре – Вашингтонның конфликтта катнашучы статусын раслаучы факт», – диде. Байден администрациясе конфликт мәйданына һава һөҗүменә каршы торучы заманча системалар китерәчәген игълан итте инде. Польшаның Жешув аэродромына бер тәүлек эчендә биштән ким булмаган хәрби транспорт самолеты төшеп утырды дигән мәгълүмат алынды. Очкычларның һәркайсы 120 тоннага кадәр йөк төягән, диләр. Германия дә һава һөҗүменә каршы торучы вәгъдә ителгән дүрт системаның берсен кичекмәстән китереп җиткерәчәген әйтте. Франция Президенты Макронның позициясе кызыклы. Моңарчы ул Путин белән телефон аша булса да элемтәгә кереп сөйләшү-килешү яклы иде. Әмма хәзер Париж лидеры Россия белән төрекләр тәкъдим иткән форматтагы сөйләшүне кире какты. Моңарчы Украинага хәрби ярдәмне кысып кына биргән французлар аны кискен арттырырга җыеналар.

Көнбатышлылар хәрби-техник ярдәмнән тыш Россиягә санкцияләр басымын көчәйтүне дә күз алдында тоталар. Санкцияләрнең тугызынчы пакеты әзерләнә. Еврокомиссия рәисе Урсула фон дер Ляйен яңа пакетның Россиягә санкцияләрдән качу мөмкинлеге калдырмаслык чараларны күз алдында тотуын хәбәр итә. Times of India – Һиндстанның иң өлкән инглиз телле газетасы: «Һиндстан Россия белән сумнарда да, рупияләрдә дә сәүдә итмәячәк. Үзара хисаплашу өчен дөньякүләм валюталар – доллар һәм евро гына кулланылачак», – дип язып чыкты. Бу рәсми хөкүмәт белдерүе түгел түгелен, әмма газета абруйлы.

Россиядә

МӘГЪНӘСЕЗЛЕК ОЗАК ҖЫЕЛДЫ

Дүшәмбедәге ракета һөҗүмнәре Россиянең эчке тормышында көчле патриотизм дулкыны кузгатырга да тиеш иде. Югыйсә махсус хәрби операциянең озакка сузылуы һәм һәрвакытта да көтелгән нәтиҗәләргә китермәве зур гына сәясәтчеләр һәм лидерлар арасында да канәгатьсезлек уятты. Рамзан Кадыйров һәм тагын берничә йогынтылы лидер югары хәрби җитәкчелекне тәнкыйтьли дә башладылар. Украина инфраструктурасының канатлы ракеталар яңгыры астында җимерелүе, чынлап та, ярыйсы гына ватанпәрвәрлек күтәрелеше китереп чыгарды. Әмма никтер финанс базарлары бу уңайдан зур төшенкелеккә бирелделәр. Спекулянтлар Россия компанияләренең акцияләреннән ашыгыч рәвештә котылырга керешге. Мәскәү биржасында котировкалар 2008 елгы дәрәҗәгә кадәр төште, диделәр. «Газпром» 22 процент кыйммәтен югалтты. Дөрес, болар барысы да – спекуляция нәтиҗәсе. Фонд базары бүген түнсә, иртәгә күтәрелә, аннан соң тагын мәтәлчек ата ала. Реаль икътисадка катнашы бик аз аның. Әмма биржада доллар һәм евро кыйммәтләнде. Финанс министрлыгының хыялы берникадәр тормышка аша башлады. Бу – инвесторларның акцияләрне сатып, активларын долларда һәм евродa сакларга омтылышы нәтиҗәсе. Гади халык өчен ул импорт товарлар инфляциясен вәгъдә итә. Евросоюзның тугызынчы пакет белән Россиягә санкция исемлегендәге товарларны кертүче бизнес һәм оешмаларга янавы болай да кыйммәтчелекнең артуына китерәчәк. Россиядә бүген бер генә төр товарларны импорт белән алыштыру уңышлы тормышка ашырыла. Виски һәм ром кебек исерткеч эчемлекләрне ватандаш бизнес күпләп җитештерә башлаган.

Дүшәмбе Куркынычсызлык советы утырышы гына түгел, Путинның сентябрьдә сайланган губернаторлар белән онлайн очрашуы да тарихка кереп калды. Мобилизациягә бәйле проблемаларны телгә алып, ул: «Монда, кызганыч, мәгънәсезлек җитәрлек. Дөресен әйткәндә, кызганычка, андый хәл башка юнәлешләрдә дә еш була. Ләкин без аның белән хәзерге кебек шөгыльләнә башламасак, беркайчан да анда күптән, күрәсең, җитәрлек күптән, тупланган проблемаларны күрә алмас идек», – диде. Мөһим, үтә мөһим белдерү бу. Әгәр Президент белдерүе дежур бер фраза гына булып калмаса, вертикаль буйлап югарыдан түбәнгә төшә башласа, Россиянең эчке тормышында тектоник үзгәрешләр китереп чыгара алыр иде. Ул үзгәрешләр уңай нәтиҗәләргә дә китерә ала, тискәре дә булуы ихтимал. Горбачев чорында, мәсәлән, кире нәтиҗә бирделәр. Нәтиҗә уңай булсын өчен сүзне гамәл белән ныгытырга кирәк булачак. «Бестолковщина» турындагы белдерү тиктомалдан гына түбәк җитәкчеләренә адресланмагандыр дип уйлыйк, чөнки күп нәрсә шулардан тора.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Ташкентка эш сәфәре барышында Үзбәкстан Президенты Шәүкәт Мирзиев белән очрашты.

«Россия белән Үзбәкстан арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуга юнәлтелгән хезмәттәшлекне үстерүгә аерым игътибар бирүегез өчен рәхмәтемне белдерәм», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Быел Россия белән Үзбәкстан арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруга 30 ел тула. «Бу гади булмаган заманда без нәтиҗәле сәүдә-икътисади һәм мәдәни-гуманитар хезмәттәшлекне саклап кала алдык», – диде Татарстан Президенты. Ул быел хезмәттәшлекнең активлашуын билгеләп үтте. Әйтик, Үзбәкстан Президенты ярдәме белән «Чирчик» химик-индустриаль технопаркы, шулай ук Җизак шәһәрендә КФУның чит илдәге беренче филиалы ачылды.

tatarstan.ru

Узган ел нәтиҗәләре буенча Татарстан белән Үзбәкстан арасында товар әйләнеше 193 млн доллардан артып китте, үсеш – 23,5 процент. Үсеш быел да дәвам итә. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, моңа үзара аралашу, килешеп эшләү, уртак сәфәрләр нәтиҗәсендә ирешеп була.

Рөстәм Миңнеханов «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме кысасында Үзбәкстан Республикасы вәкиленең актив эше өчен Шәүкәт Мирзиевка аерым рәхмәт белдерде, Татарстан Президенты аны Владимир Путин кушуы буенча җитәкли.

Сүз уңаеннан, Рөстәм Миңнеханов Ангрен шәһәрендә резина-техник заводта да булды.

«Birinchi Rezinotexnika Zavodi» җәмгыяте конвейер ленталары, авыл хуҗалыгы һәм автомобиль шиннары җитештерә. Предприятие елына 3 млн автомобиль шины һәм 200 мең авыл хуҗалыгы шины җитештерә. Татарстан Президентына завод цехларын күрсәттеләр һәм җитештерү технологиясенең үзенчәлекләре турында сөйләделәр.

Дуслык күпере

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Төрекмәнстанның Казандагы Генераль консулы Гуйч Гәрәев белән очрашты.

Парламент җитәкчесе дипломатны үз вазыйфасына керешүе белән котлады, шулай ук Россия – Төрекмәнстан стратегик партнерлыгы кысасында Татарстан белән Төрекмәнстан арасындагы дустанә мөнәсәбәтләрне, шул исәптән парламентара элемтәләрне ныгытуга ышаныч белдерде.

Төрекмәнстан һәрвакыт Татарстанның төп тышкы сәүдә партнерларының берсе булды. Мисалга, узган ел товар әйләнеше 77,5 млн долларны тәшкил иткән. «Безнең сәүдә-икътисади һәм мәдәни өлкәләрдә ныклы мөнәсәбәтләр урнашты, күп кенә уртак проектлар гамәлгә ашырыла», – дип ассызыклады Фәрит Мөхәммәтшин, Генконсулны сәламләп. Татарстан белән Төрекмәнстанның гуманитар элемтәләре дә көчле. Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, Татарстанда яшәүче 173 милләт вәкилен берләштерүче Татарстан халыклары ассамблеясы составында төрекмән милли-мәдәни берләшмәсе актив эшли.

Парламент башлыгы сүзләренчә, хәзерге вакытта, Россия – Төрекмәнстан диалогы кысасында парламентара хезмәттәшлекне киңәйтү мәсьәләләре карала. Парламентара бәйләнешләрне активлаштыру тәкъдимен Төрекмәнстан парламентының югары палатасы рәисе Горбангулы Бәрдемөхәммәдов Татарстанга визиты вакытында җиткергән булган. Сүз уңаеннан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән Төрекмәнстан Мәҗлесе арасында хезмәттәшлек турында килешү 10 ел элек имзаланган булган.

«Без хезмәттәшлек өчен һәрвакыт ачык», – диде Фәрит Мөхәммәтшин һәм Генконсулны парламент утырышына чакырды. Анда Татарстан Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тыңлаячаклар.

Коммуналь хуҗалык

КЫЙММӘТЛЕ ҖЫЛЫЛЫК

Сентябрь аена килгән торак-коммуналь түләүләр квитанциясе күпләрне гаҗәпкә калдырган. Җылылык өчен исәпләнгән сумма 2 мең сумны узып китә икән. Казанның Киров районында яшәүчеләр аптырашта калган. Урамда артык салкыннар да булмады, ди алар. Ә түләвен барыбер түлисе.

Зарланучыларның күбесенең фатирларына җылылык үзәкләштерелгән система буенча килә. Шәхси җылыту казаны булганнар исә, түләү квитанциясендә үзгәреш сизмәдек, ди.

– Без әле дә фатирга җылы кушмаган. Көннәр матур торгач, өйдә җылы. Газны кушарга уйлаган да юк. Баштарак шәхси казанлы фатир икән дип борчылган идек, хәзер сөенеп туя алмыйбыз. Бик уңайлы икән. Җылы су ел әйләнәсе бетми, – ди Казанның Фучик урамындагы бер йортта яшәүче Гөлсирә Исрафилова.

Элеккеге иске йортларда җылылык әле дә үзәкләштерелгән система буенча килә. Күбесендә һава торышын көйләүче махсус җиһазлар да куеп булмый. Казанның Можайск урамында да шул ук хәл. Биредә ике катлы йортта яшәүчеләр җылылык өчен түләүгә килгән квитанциягә риза түгел.

Үзен Гөлсәрия Смирнова дип таныштырган газета укучыбыз йортларына сентябрь ахырында гына җылылык бирелгәнен әйтә.

– 3 көн җылы бирделәр, шуның өчен без 2 мең сумга якын акча түләргә тиеш хәзер. Өйдәге батареяларга тотынып та булмый. Әле ярый исәпләгеч тормый. Аны куйган булсалар, бу сумма тагын да күбрәк килер иде. Тик безнең түлисебез килми. Нишләргә дә белгән юк. Бу йортта инде яшьләр калмады да. Пенсионерлар яшибез. Кышка керсәң, бөтен акча түләүгә китә, – ди ул.

Баксаң, бу йортларның подвалы да юк икән. Булса, исәпләгечләр куя алган булырлар иде. Шуңа да биредә яшәүчеләр 8 ай буе җылылык өчен бертөрле сумма түләргә мәҗбүр. Бу дөрес хәлме?

Татарстанның Дәүләт торак инспекциясендә бу хакта беләләр икән инде. Алар безгә җылылык өчен түләү суммаларын шәрехләде. Фатирында шәхси казаны булган кешеләр урамда салкыннар башлангач кына күбрәк түли башлый. Ә инде йортта гомуми исәпләгечләр куелса, алар җылылык өчен урамдагы һава торышына бәйле рәвештә түли. Әйтик, көзге айларда әзрәк, кыш көне күбрәк, язга таба тагын кимрәк түләячәкләр. Әгәр йортта бөтенләй берннди дә җиһазлар куелмаса, монда яшәүчеләргә җылылык өчен ай саен бер сумма килә. Биредә йортта тотылган җылылыкны һәр кешегә фатирның мәйданына карап бүләләр.

Түләүне ничек итеп киметеп була соң? Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты матбугат үзәгендә аңлатуларынча, әгәр торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары гаиләнең җыелма кеременең 21 процентыннан артып китсә, кеше субсидия алу өчен социаль яклау органнарына мөрәҗәгать итә ала. Кирәкле документларны тапшыргач, ай саен исәп-хисап счетына җылылык өчен түләгәннең бер өлеше кире кайтып барачак.

Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге башкарма директоры Дмитрий Романов исә, йортларда һава торышын көйләүче махсус төймәләр урнаштырырга кирәк, дигән фикердә.

– Андый төймә урнаштырылган йортларда һава температурасы минустан плюска күчкәндә хәтта 25–30 процентка кадәр экономияләргә була. Фатирлардагы батареяларга хәзер махсус төймәләр куела башлады. Аның ярдәмендә җылыны көйләп була, – ди ул. – Түләү кәгазьләрендәге саннарга игътибарлы булырга кирәк. Әгәр идарәче оешма җибәргән квитанциядә зур суммалар булса, идарәче оешмадан бу хакта аңлатуларын сорагыз. Йортыгызга исәпләгечләр куелган икән, алдагы айдагы күрсәткечләр белән хәзергесен чагыштырыгыз. Дөрес түгел дип уйлыйсыз икән, идарәче оешмага мөрәҗәгать итегез. Анда эшегез уңмаса, Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БОЗАУ ДА БУЛСЫН, ТАНА ДА БУЛСЫН

Яшәеш

Фермаларда хәзер ел әйләнәсе урак өсте. «Урак» дигәнем күчерелмә мәгънәдә, бозаулату чорын күз алдында тотуым. Элек фермаларда сыерларны бозаулату чоры күбесенчә кыш айларына туры килә иде. «Хәзер инде алай гына эшләп булмый, терлек саны күп, шуңа күрә бездә ел әйләнәсе бозаулату чоры, ай саен кимендә 100 бозау алуны бурыч итеп куйдык», – ди Балтач районының «Татарстан» хуҗалыгы баш зоотехнигы Ленар Мөхәммәтҗанов. Ә моның үз мәшәкатьләре, үз проблемалары икән.



Автор фотосы

– Бозаулату бүлеге күптән түгел төзелеп, заманча таләпләргә җавап бирсә дә, моның кадәр терлекне бер урында гына бозаулату мөмкин түгел, инфекция-авырулар куркынычын арттыра иде, – дип дәвам итә Ленар. – Шуңа күрә дүрт айга бер тапкыр бозаулату торагын ял иттерү өчен элекке 200 башка исәпләнгән сыер абзарында тагын бер бозаулату бүлеге оештырдык. Декабрьдә Сәрдегән фермасында шундый тагын бер торак эшли башлаячак. Терлек саны даими артып торганда шунсыз булмый.

Менә шулай, бозаулар турында биредә инде туганчы ук кайгырта башлыйлар. Яңа туган бозауларны да иренмичә, вакланып тәрбиялиләр, бөтенесен төгәл үтәргә тырышалар. Туып, ярты сәгать үтүгә, туңдырылган угыз сөтен җебетеп, 4 литр күләмендә, 6 сәгатьтән соң ике литр эчертәләр. Сөтне икенче-өченче бозаулаган сыерныкын алабыз, чөнки анда иммунитетка йогынты ясый торган элементлар күп, диләр. Ике тапкыр үз вакытында (сәгатьләрен дә, күләмен дә төгәл үтәп) сыйфатлы угыз сөте эчертү бик мөһим икән, хәтта ике көннән соң бозаулардан кан алып, эчерткәннәрме-юкмы икәнен тикшертәләр, ул исә анализларда күренә. Анализлар уңай чыкса, ягъни угыз сөте эчертелгән булса, терлекчегә премия дә каралган.

Элекке кебек, яңа бозаулаган сыерлар да су һәм коры печәнгә генә «карап тормый». Аларның да организмы тернәкләндерүгә мохтаҗ, диләр.

– Бозаулауга һәр сыерга, 40 литр суга кушып, энергетик эчертәләр, авызына организмда калий-фосфор нисбәтен көйли торган дару-өстәмә салалар. Өченче көнендә сыерлар комплекска күчерелә. Аерым төркем җыйналып, анда да маллар ветеринария табибы каравында кала. 21 көнгә кадәр аерым, көчәйтелгән рацион белән ашатыла. Сыерга организмын тернәкләндерү өчен бөтен шартлар тудырыла, – ди Ленар.

2021 елның гыйнвар – февраль аенда, йогышлы авыру кереп, хуҗалыкта бозаулар шактый үлә. Бу хәл бүтән кабатланмасын өчен соңгы ел ярымда биредә ниләр генә эшләнмәгән: йөзәр башка исәпләнгән элекке ике сыер абзарына реконструкция ясап, бозаулар өчен махсус читлекләр ясалган. Яңа туган бозауларны, көнләп аерып, шунда туплыйлар. Сөт кухнясы ясалган, сөтне бактерияләрдән чистарта торган җайланма, Яңа Зеландиядән 240 махсус пластик шешә кайтарылган. 4 литр сөт сыйдырышлы ул шешәләр генә дә өч миллион сумга төшкән. Бу чыгымнар үзен аклый, күрелгән чаралар нәтиҗәсез калмады, быел бозауларның сакланышы – 98 процент, диләр. 120шәр шешә сыешлы махсус ике станок ясатканнар, автомат югыч урнаштырганнар, әлеге шешәләргә кидерелә торган имезлекләрне юдыру өчен дә махсус ванналар куелган. Алар барысы да һәр кулланылыштан соң җылы су, күбек белән юыла, дезинфекцияләнә, икенче сменага килүчеләр эшне аларны кабат юдырудан башлый. Бу кадәресе авыруларны булдырмас өчен кирәк булса, аларны сәламәт, мул продукция бирергә сәләтле терлек итеп үстерү өчен кечкенә бозау чагыннан ук дөрес ашатуга да зур игътибар бирелә. Дүртенче көндә инде бозауларга 400 грамм исәбеннән махсус рацион белән төзелгән коры азык бирелә башлый. Арттыра барып, әлеге сан 1,5 килограммга җитә. Ай ярымнан монокормга күчерәләр.

– Безнең бурыч: таналарның көндәлек үсешен 950 граммга җиткереп, 13 айда каплатырлык итү. Бүген инде бу сан – 890–940 грамм, – ди Ленар.

2013 елдан бирле сөт юнәлешендәге генетика белән шөгыльләнүче хуҗалыкта соңгы елларда тана бозаулар туугa гарантия бирә торган Голландия – Америка үгезләре спермалары белән эшлиләр. Бу – 1600 сыерга исәпләнгән яңа мегаферманы үз көтүләрендәге терлек хисабына тутыруда бер юл.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КЫЗЛАР КАЙГЫСЫ ТҮГЕЛ!

Белем һәр тәрбия

Җәмгыятьтә, егетләр яки кызлар гына аерым укыган мәктәпләрдә уку кызык түгелдер, алар үз эченә бикләнеп үсә, дигән фикер яши. Гендерлы, ягъни җенескә бүлеп укытуның нинди тискәре һәм уңай яклары бар? Казандагы ир малайлар укый торган 7 нче лицей-интернатка менә шуларны белү өчен килдек тә инде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Укытучы өйгә килә

Хәзерге вакытта лицей-интернатта илнең һәм республиканың төрле төбәкләреннән 230 бала укый. Мәскәү, Владимир шәһәрләре, Әстерханнан килүчеләр дә бар. Монда мари, чуаш, рус, татар, таҗик, төрек, үзбәк һәм башка милләт балалары укый. Күбрәк татарча сөйләшәләр. Татар теле белән әдәбият дәресләре атнага өч сәгать керә.

Лицей директоры Алмаз Шакирҗанов әйтүенчә, әти-әниләр уку йортын яхшы белем һәм тәрбия өчен сайлый. Лицейны тәмамлаучылар Татарстанда гына түгел, Мәскәү, Петербург һәм чит ил вузларында укуын дәвам итә. Монысы да әти-әниләр өчен мөһим. «Укып бетергәч, кире кайтучылар да, читтә калучылар да бар», – ди Алмаз Шакирҗанов.

Башка мәктәпләрдән аермалы буларак, мондагы укытучылар балаларның өйләренә хәл белешергә йөри. Мөгаллимнәр аларның яшәү шартларын тикшерү өчен түгел, гаиләдәге мөнәсәбәтләрне, әти-әниләрнең уку йортыннан нәрсә көтүен белү өчен бара. Укытучы кунакка килеп киткәч, аңа ышаныч тагын да арта.

Малай-шалайлармы?

Малайлар җыелган җирдә тәртип саклау бер дә җиңел түгелдер кебек тоела. Алар бит әтәчләнергә ярата.

– Бездә тәртипсез балалар юк. Алар укырга дип килә. Лицейдан чыккан балалар тәрбиясе, телен, милләтен, туган җирен яратуы белән аерылып торсын! Яхшы әти булсын дигән максат куябыз. Укытучы үрнәк булса, балага сүз белән аңлатырга да кирәкми. Бездә мөгаллимнәр үз үрнәгендә тәрбияли, – ди директор.

Директорның милли мәсьәләләр буенча урынбасары, сыйныф җитәкчесе Алмаз Мансуров лицейда ун еллап эшли икән инде.

– Болай эшләсәң – начар, тегеләй эшләсәң, әйбәт дип әйтеп булмый. Чикләүләр куярга тырышмыйбыз, кешене мохит тәрбияли, – ди Алмаз Мансуров. – Төрле бала бар. Егетләр нәрсәдер эшләсә, әйтик, бераз бер-берсе белән көрәшеп алса, әти-әниләргә хәбәр итмим. Алар үзләре хәл итәргә тиеш. Килешенгән кагыйдәләр бар. «Ни өчен шулай эшләдең?» – дип фикерен сорашам. Егетләр ярышырга ярата. Әтәчләнү дигән нәрсә башта булып ала инде ул. Алар безгә 5 нче сыйныфка төрле мәктәптән килә бит. Тәртипләре дә, карашлары да төрлечә була. Бездә укып, кысага керәләр, кечерәкләр олыракларга абый дип дәшә. Мин бер ел гади мәктәптә эшләп карадым. Анда балаларны ашханәдә үзләрен генә калдырып китеп булмый, шаулаша башлыйлар иде. Бездә исә табынга утыргач, бер тавышлары да чыкмый. Тәнәфестә коридордан узсагыз, уйнаган, йөгергән, көрәшкән малайларны да күрерсез. Егетләр актив, әмма алар бер-берсенә карата җылы мөнәсәбәттә. Өлкәннәр кечерәкләргә өй эше эшләргә булыша.

Башта уку гына

Әнә коридорда бер малай бик бирелеп китап укый. Мондый сирәк очрый торган күренешне игътибарсыз калдырып буламыни?! Яшел Үзәннән килгән 5 нче сыйныф укучысы Ибраһим Сәлахов икән.

– Бүлмәбездә китап уку буенча икенче урын алган идем. Бу тарихи китапны «башкан» (кече сыйныфларга билгеләгән өлкән сыйныф укучысы. – **Авт.**) бүләк итте миңа. Бик кызыкка охшап тора, – ди Ибраһим. – Әти-әнием бу лицейга барырга тәкъдим иткәч, каршы килмәдем. Монда укыйм һәм яшим. Өйне бераз сагынам инде. Тормышка мин күпмедер дәрәҗәдә әзер. Әни чалбар үтүкләргә өйрәтте, ботинкаларны да үзем чистартам.

Самат Хәмидуллин да, Әсгать Шәмсиев тә – Казан егетләре. Икесе дә программист булырга җыена. Татарчаны да ярыйсы гына беләләр. «Укырга кызык. Егетләр генә уку бер дә сәер түгел», – ди Әсгать.

Коридорда башка малайларны да туктатып сөйләштек, беренче мәхәббәт турында да тел төпләрен тикшереп карадык. Янәсе, кызларның чәчләрен тартмагач, аякларына басмагач, нәрсә була инде ул? Арада кайберләре серле генә елмаеп куйса, «Бездә – кызлар түгел, уку кайгысы», – диючеләр дә булды.

Тәрбияче «абый»лар

Төрек егете Алтун Әбүбәкер дә шушы лицейда белем алган. Хәзер шунда укучыларны робот техникасына өйрәтә, шул ук вакытта тәрбияче дә.

– Башта кызлар белән аралашырга авыррак, әмма бер елда бар да тәртипкә салына. Укып бетергәч, гашыйк буласың да өйләнәсең. Менә бу беренче һәм гомерлек мәхәббәт була, – ди Әбүбәкер, елмаеп.

Тәрбияче буларак аннан малайларның тәртибе турында кызыксындык. «Башта бәдрәфкә бара, теш чистарта, карават җыештыра белмиләр, барысына да өйрәтәбез. Сугышалар дип әйтә алмыйм. Кечерәкләргә өлкән сыйныф укучылары беркетелгән, аларны тәртиптә тоталар», – ди Әбүбәкер Алтун.

Казан егете Искәндәр Сөнгатов та шушы лицейны тәмамлаган. Хәзер ул информатика дәресләрен укыта, тәрбияче вазыйфасын башкара.

– Малайлар бер яшьтә булгач, кызыксынулары охшаш. Шуңа күрә аралашырга күпкә җайлырак. Бер-берсенә булышалар. Аерым укытуның яхшы якларын күбрәк күрәм, – ди Искәндәр.

Сәрия МИФТАХОВА

БЕЛГЕЧ ФИКЕРЕ

7 лицей-интернат директорының укыту эшләре буенча урынбасары Таһир ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНның кызлар һәм егетләр лицеенда эшләү тәҗрибәсе бар.

– Кызлар һәм ир малайлар төрлечә «өлгерә»ләр. Алар мәгълүматны төрлечә кабул итә. Укытуда кызларга – бер, егетләргә икенче алымнар туры килергә мөмкин. Һәм бу тәрбиядә дә шулай. Бергә укыган сыйныфта кызларга гына аңлата торган әйберне малайларга аңлатып булмый яки киресенчә. Алар үз фикерен әйтергә читенсенә. Аерым укыганда, оялып тормыйлар. Кайберәүләр, җенес ягыннан аерым укыганнар алга таба кызлар яки егетләр белән уртак тел таба алмый, дип борчыла. Бездә интернет, социаль челтәрләр бар. Алар өйләренә дә кайтып йөриләр. Гади мәктәптә кызлар егетләрнең яки, киресенчә, бер-берсенең начар ягын күреп, хөрмәте кимергә мөмкин. Аерым укыганда, 18–19 яшьтә инде андый проблеманы күрми кала. Егетләребезнең, өйләнгәч, аерылышу күрсәткече бик түбән. Россиядә өйләнешүчеләрнең яртысының гаиләсе таркалса, бездә бу – 10 процент чамасы. Алар гаилә коруга җитди карыйлар.

Кызлар лицеенда эшләгәндә, бер генә тискәре ягын күрдем. Кызлар малайлар янәшәсендә үзләренең тышкы кыяфәтенә күбрәк игътибар бирергә тырыша. Малайлар булмагач, бу хакта уйламыйлар.

Шалтыратыргамы, шалтыратмаскамы?

Татарстанда психологик ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләр саны арткан. Шул уңайдан республикада яшьләр ышаныч телефоны эшли башлады. «Кайнар линия»гә күбрәк нинди сораулар белән шалтыраталар? Яшьләрне бүген нинди проблемалар борчый?

«Кайнар линия»гә узган ел 32 меңләп кеше мөрәҗәгать иткән булса, быел тугыз айда 30 меңнән артык кеше ярдәм сорап шалтыраткан. «Ышаныч» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге директоры Елена Овчинникова әйтүенчә, иң күп мөрәҗәгатьләр – әти-әниләр һәм балалар проблемалары, халыкның бүгенге вазгыятькә бәйле борчылуы һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәт.

Психолог, Казан инновацияләр университеты доценты Надежда Ванюхина психологка мөрәҗәгать итүчеләрнең арту сәбәпләрен атады.

– Беренчедән, кешеләр психологларга ышана башлады. Кешенең психик сәламәтлеге турында кайгыртуы артты. Икенчедән, белгечләргә барлык кеше дә мөрәҗәгать итә ала. Бүгенге вазгыять халыкны кабат борчуга салды, тетрәнергә мәҗбүр итте. Хәзерге тормыш бик үзгәрде: ул 20–30, хәтта 10 ел элеккеге кебек тә түгел. Бик кызу һәм киеренке чорда яшибез. Тышкы сәяси вазгыять бик катлаулы. Көн саен куркыныч хәбәрләр алып торабыз. Бу, әлбәттә, кешегә тәэсир итми калмый. Мондый чорда психологка мөрәҗәгать итү – эмоциональ халәтне яхшырту өчен иң нәтиҗәле ысулларның берсе. Әгәр дә кеше борчу, паника, стресстан мөстәкыйль рәвештә чыга алмый икән, һичшиксез, психологлар ярдәменнән файдаланырга кирәк, – диде ул.

Яшьләрне бүген нәрсә борчый? Казанда яшәүче 24 яшьлек Алия ил-көн вакыйгалары аркасында тынычлык таба алмавын әйтте.

– Мин үземнең шәхси тормышымдагы тирән үзгәрешләрне дә бик авыр кичерәм. Илдәге вакыйгалар мине бөтенләй тетрәндерде. Мондый вакытта ничек тыныч калып була инде? Гел яңалыклар укыйм, видеолар карыйм да төшенкелеккә биреләм. Киләчәк турында уйлар хәлемне начарайта. Бу халәттән чыгу өчен белгечкә дә мөрәҗәгать итеп карадым. Ул миңа яңалыкларны мөмкин кадәр азрак укырга, спорт белән шөгыльләнергә, яңа хобби табарга киңәш итте, – дип сөйләде Алия.

21 яшьлек Рәмзия көндәлек тормышка кызыксынуын югалткан.

– Элек кызык тоелган әйберләр хәзер бернинди шатлык китерми. Мин сәяхәт итәргә, чит илдә белем алырга хыялландым, ләкин безне боларның барысыннан да мәхрүм итәләр кебек. Моннан соң безне нинди тормыш көтә? Нәрсәгә әзер булырга тиешбез? Бу билгесезлек мине куркыта һәм өметемне өзә, – диде ул.

Психологик ярдәм кирәк булса, 14 яшьтән алып 35 яшькә кадәрге татарстанлылар 8-800-555-22-20 телефонына шалтырата ала. Шәхси бушлай консультациягә «Ышаныч» үзәгенең «ВКонтакте» төркеме аша язылырга яки белгеч белән онлайн аралашырга да мөмкин.

Ләйсән САФИНА

Мин кулыма китап алдым

ТӘРҖЕМӘМЕ, АУДАРУМЫ?

Китап белән укучы арасын бәйләп торучы тагын бер нәрсә бар әле ул. Әдәби тәрҗемә. Урынлы кулланган очракта, әлбәттә. Моны ике төргә бүлеп карарга мөмкиндер: татарчага тәрҗемә итү һәм чит телләргә аудару.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарчага тәрҗемә итү. Минем бик күп шагыйрьләрне һәм язучыларны татарчага әйләндергәнем бар. Бер нәрсәсе дә юк кебек инде аның. Барысы да әзер, язылган. Пешкән ашны бер савыттан икенчесенә күчергән кебек кенә. Ләкин боларның барысы да үзем өчен, чит халык авторларын аңлау, аларның язу стилендәге үзенчәлекләрен өйрәнү өчен генә. Үзенә күрә әдәби күнекмә рәвешендә. Мин аларны беркемгә дә күрсәтмим, беркая да чыгармыйм. Күп очракта җуеп ташлыйм.

Үзең өчен эшләгәнгә генә шулай җиңел тоела ул. Әгәр китап итеп чыгарырга уйласам, мин бик нык тырышырга, һәр сүзен мең кат үлчәргә, һәр җөмләсен кырык төрлегә үзгәртеп карарга мәҗбүр булыр идем. Чит милләт авторының стилен дә сакларга, фикерен дә җиткерергә, аны татарча матур итеп яңгыратырга да кирәк бит. Бер сүз белән әйткәндә, тәрҗемә ул узып барышлый гына эшли торган нәрсә түгел, ул – үзе бер иҗат төре.

Менә монда инде, бәлки, һәр эшне башлагандагы кебек үктер, бер сорау калкып чыга: максаты нинди? Төрлечә булырга мөмкин: юбилейлар уңаеннан, ниндидер милләт әдәбияты белән бәйләнешләрне көйләү йөзеннән, «син – миңа, мин – сиңа» дигәнрәк иҗади бартер рәвешендә, тагын әллә нәрсәләр… Болары да кирәктер, әмма алар – иҗади оешмаларның яки аерым шәхесләрнең көнкүреш мәсьәләләрен хәл итү өчен кулланыла торган кыска вакытлы максат. Укучыны татар китабыннан аермау өчен эшләнгән тәрҗемәләр бөтенләй башка төрле була. Шул үзенчәлекләргә беркадәр тукталып китәргә телим.

Минем инде бу хакта күп тапкырлар әйткәнем бар, ләкин бөтен кеше дә бөтен язмаларымны да укып барадыр дип уйламыйм, шуңа тагын кабатларга мәҗбүрмен. Әгәр укучыларның татар китабына булган кызыксынуын үстерергә теләсәк, без чит әдәбиятларның иң популяр, иң кызыклы китапларын руслардан күпкә алданрак тәрҗемә итәргә тиешбез. Бу – иң мөһиме. Руслардан соңга калдыңмы – мәгънәсе югала.

Мисалга мин «Гарри Поттер»ны китерәм. Дөнья әдәбиятында бер феномен сыман булды бит инде ул. Балалар да, үсмерләр дә, өлкәннәр дә яратып укый торган бик популяр китапка әйләнде. Менә шуның, әйтик, бишенче томы иң беренчеләрдән булып татар теленә тәрҗемә ителеп чыкты ди. Татар баласы, беләсезме, ничек горурланып күтәреп йөртер иде ул китапны! Ә башка милләттән булган яшьтәшләре, сыйныфташлары көнләшеп туялмас иде: «Нәрсә турында ул? Кыскача эчтәлеген генә булса да сөйлә әле безгә дә…» Бу очракта инде әти-әниләр дә: «Нигә кирәк инде ул татар теле…» – дияр алдыннан аз гына уйланып торырлар да дәшми калырлар иде. Гади бер китапны нәкъ үз вакытында тәрҗемә итү телнең, әдәбиятның, милләтнең абруен күтәрүгә юнәлтелгән әллә күпме чаралардан да әһәмиятлерәк булырга мөмкин.

Бу бик гади эш түгел инде, дөньяда популярлык яулаган әсәрләрне даими рәвештә күзәтеп баруны таләп итә, икенче төрле әйтсәк, чит илләрнең, чит халыкларның китап базарын өйрәнүне сорый. Хәер, үзен хөрмәт иткән һәр автор, һәр нәшрият шундый нәрсә белән шөгыльләнә торгандыр инде ул. Икенчедән, авторлык хокуклары мәсьәләсе калкып чыга. Андый популяр әсәрләрнең бәясе бик арзан булмый. Акча һәркемгә дә кадерле. Ләкин кызганырга кирәкме икән? Әгәр шул бер тәрҗемә нәтиҗәлелегә ягыннан әллә күпме чараны алыштыра ала икән, акча кызганырга кирәкмидер. «Хәерченең акчасын арзан тауар бетергән», – дип юкка гына әйтмәгәннәр бит инде. Аннан соң, һәрбер уңыш өчен күпмедер түләргә кирәк. Зуррак уңышның бәясе югарырак.

Рус телендә язган авторларны татарчага аударуның мәгънәсен күрмим. Әйе, мин кечкенә чагымда хәтта Пушкинны да беренче тапкыр татар телендә укыдым. Ләкин бүген заман башка. Бүген русча белмәгән татар юк. Бот буе татар балалары да русча сөйләшеп йөри. Татарча да беләләр. Авылда бу. Хәтта әби-бабайлар да… Әби-бабайлар безнең чордашлар бит инде. Хәзер мин үзем дә бабай. Шулай булгач… Һәрхәлдә, мин Пушкинны да, Есенинны да татарча укымыйм инде. Тәрҗемәчеләргә авыр ишетелмәсен, тик аларны татарчага әйләндерү – мәгънәсез шөгыль. Заманында мин Есенинны тәрҗемә иттем. Үзем өчен. Уңышлыракларыннан бер-ике шигырьне китабыма да кертеп җибәрдем. Шул җитә. Күләме буенча исәпләгәндә, китап чыгарырлык мөмкинлек тә бар иде. Гөнаһыннан башаяк дип, аларын яндырдым. Дөрес эшләгәнмен дип уйлыйм. Үземне ничек кенә югары бәяләсәм дә, мин барыбер Есенин түгел бит инде. Есенинны русча укырга кирәк. Пушкинны да. Гомумән, мөмкинлегең булганда һәр авторны оригиналда укырга кирәк.

Яшьрәк чакта хәтта Байрон шигырьләрен дә тәрҗемә итеп караган булды. Русчадан. Ахмаклык инде бу. Тавык шулпасының шулпасы дигән сыманрак нәрсә килеп чыга. Әле аны кемдер татарчадан башка телгә аударса, тагын да кызыграк булыр иде. Заманында мин Әнгам Атнабаевның русчага әйләндерелгән шигырен кабат татарчага тәрҗемә иттем. Кызык өчен. Укып күрсәткән идем, Әнгам абый үзе танымады. Шундый хәлләр.

Татарчага тәрҗемә бары тик оригиналдан гына булырга тиештер. Шигырьләрне – бигрәк тә. Чәчмә әсәрләрне дә. Һәрхәлдә, төрки телләрдә язылган әсәрләр русчага әйләндергәндә ничектер… белмим… хәтта сүз дә табып булмый бугай… «слащаво» булып яңгырый. Тәмле телле инде шундый. Сентименталь. Русчага тәрҗемә иткәндә әнә шул тәмле теллелеген юкка чыгаралар. Җөмләләр конкретрак булып кала. Русча әйбәт ишетелә ул, тик менә нәрсәседер югала. Әйтик, төрек яки казах язучысының әсәрен русчадан тәрҗемә итәсең икән, син әнә шул югалтулардан торган нәрсәне татарчага әйләндерәсең. Мин моны бик белеп әйтәм, авызым пешкәне бар.

Бу сүзләр драматургиягә кагылмый. Пьесалар һәм киносценарийлар әдәбиятка керми бит инде, керсә дә, шартлы рәвештә генә. Һәрхәлдә, бу өлкәдәге әсәрләрдә характерлар, вакыйгалар төп урынны тота. Әдәби тел анда – икенчел күренеш. Тел анда әдәбиятның миллилегеннән бигрәк, характерларның үзенчәлегенә бәйле. «Әлдермештән Әлмәндәр»не, мәсәлән, ашык-пошык тәрҗемә итеп кенә нинди телдә чыгарсаң да, ул бәясен югалтмый.

Татарчага тәрҗемә ул – әдәбиятыбызны күтәрүдән бигрәк, үз телебездә укый торган кешеләрне саклауга һәм күбәйтүгә, димәк, телебезне популярлаштыруга, аралашу даирәсен (укучы чит ил әдәбияты белән татар телендә аралаша) һәм милләтнең абруен тотуга юнәлтелгән күренеш. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш кебек.

Татарчадан тәрҗемә. Шундыйрак бер кызык феномен бар: күп очракта татар укучысы сиңа игътибар итсен өчен, китапларыңның чит телдә басылуы кирәк. Һич югында башкорт телендә. Яки казахта. Үзбәктә. Шул да үзенекен итә. Без үз талантларыбызны турыдан-туры күрә белмибез, без аларны читләр аша күрәбез. Минем «Убырлар уянган чак» романы төрек телендә чыккач, аңа кызыксыну бермә-бер артты. Ярты ел эчендә өч меңгә якын электрон китап сатып алдылар. Хәтта рецензия язучылар да булды. Югыйсә бу уникенче ел элек язылып, әллә кайларда дөнья күргән әсәр бит инде. Яңа түгел. Тик менә әсәрнең чит телгә тәрҗемә ителү хәбәре аны яңартып җибәрә. Укучының игътибарын арттыра. Шул рәвешле, чит телләргә тәрҗемә итү татар әдәбиятын бүтән халыкларга күрсәтеп кенә калмый, ә үзебезнең укучыларны да кузгатып җибәрә. Шул җәһәттән ул икеләтә файдалы. Шуңа бу мәсьәләдә артык тукталып торасым килми. Тәрҗемә итәргә кирәк. Күп итеп. Классикларны да, бүгенге чор авторларын да. Бу очракта сан сыйфатка әйләнә.

Марат КӘБИРОВ

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Лампочка

Адәм баласы кызык бит инде ул. «Ярамый» диелгән нәрсәләрне гел эшләп карарга тырыша. Үзем дә адәм баласы инде мин. Ярамаган ризык татлырак, ярамаган гамәл кызыклырак, ярамаган ярлар сөйкемлерәк булып тоела. Ризыгын гына алыйк инде. Менә аның сиңа ярамаганын белмәсәң, борылып та карамыйсың. Кирәкми ул сиңа, бар ни, юк ни – барыбер. Хәтта ач вакытыңда да андый нәрсәгә якын килмәскә мөмкинсең. Ләкин шул ризыкны сиңа ашарга ярамаганын белеп калсаңмы! Аннан да тәмлерәк нәрсә юктыр шикелле тоела башлый. Тик әле мин башка нәрсә турында сөйлим.

Менә миңа да алай эшләргә ярамый иде. Шулай дип әйттеләр дә инде: «Мондый шаяруны сәхнәгә чыгарырга ярамый», – диделәр. Ярый, алай икән, дип тукталып калгандыр дип уйлыйсызмы? Юк! Белмәгән кеше өчен инде монысы: мин күп еллар буена күренекле артистларның концертларын алып баручы конферансье дип аталган тел бистәсе булып эшләдем, кайчагында үзем дә юмористик концертлар оештырдым. Менә шундый концертларның берсендә теге «ярамый»ны бозып: «Кешенең кулыннан килмәгән эшләр була. Менә әгәр сез авызыгызга лампочка кабасыз икән, аны берничек тә чыгара алмаячаксыз. Әгәр чыгара аласыз икән, бүгенге концерт акчасын сезгә бирәм», – дип ычкындырдым. Һәм моның бары тик шаяру гына икәнен кисәттем. Берүк алай эшли күрмәгез, беркайчан да авызга лампочка кабарга ярамый! Ярамый! Зал аңлады, шаяру икәнен белеп итагать саклау өчен генә көлешеп алдылар. Көлдерүгә исәпләнгән түгел, бер темадан икенчесенә күчүне җайлаган җөмлә генә иде бу. Булды да үтте. Яхшы бөтенесе дә. Ләкин…

Берничә минутка сәхнәдән чыгып торган арада иҗаттәшларымның берсе шелтәләп куйды: «Бүгенге тамаша акчасын аларга биреп бетерсәң, без бушка эшлибезмени?» Юморны аңламый торганрак егет инде. Юмор аңламаган кешеләрдән дә яхшырак көлдерә белүче юк бугай бу дөньяда. Мин аның җитди йөзенә карап кычкырып көлеп җибәрдем дә күтәренке кәеф белән кабат сәхнәгә чыгып киттем. Мин акчасыз калудан курыкмый идем.

Лампочка авызга җиңел керә ул, рәвеше дә шундый, груша сыманрак – сөзәк кенә күтәрелеп китә. Хикмәте анда гына түгел әле, йөз мускуллары башта йомшарган була, сыгылмалы. Шуңа күрә, авызыңны күпме зур итеп ачарга телисең, шулкадәр ачасың. Табигый мөмкинлекләреңә карап, әлбәттә. Ләкин авызыңа лампочка кергәч, мускулларда киеренкелек арта, алар кысыла башлый. Моңа табигатьтән бирелгән инстинкт та кушыла – авызыңа ризык капкансың икән, ул ябылырга тиеш. Шул рәвешле, йөздәге мускуллар авызны ябу өчен тартыша башлый. Ә ул ябылып бетми. Лампочка ирек бирми. Киеренкелек арта. Кеше аптырауга кала: ныграк тартасың икән, аның нәзек пыяласы ватылырга мөмкин, ә аз гына тартуның файдасы юк.

Мондый очракта башта тынычланырга кирәк, игътибарыңны башка нәрсәләргә юнәлтергә, авызыңда лампочка бар икәнен онытырга. Шул вакытта йөз мускуллары йомшара төшә һәм аны тартып чыгару җиңелләшә. Яки таза йомшак кульъяулыкны лампочка артыннан уратып тартырга. Бер сүз белән әйткәндә, авызыңдагы лампочканы кульъяулыкка төрәсең дә тартып чыгарасың. Ватылган очракта, пыяла кульъяулык эчендә кала, авызыңны яраламый.

Концерт ярыйсы гына узды. Фотога төшү, автограф кую кебек матур мәшәкатьләрдән арынып гримеркага керсәм, бүлмәдә дүрт кеше утыра. Башта мин сәерсенеп киттем, әллә ялгыш бүлмәне бутадыммы дип ишеккә карап алдым. Юк, дөрес кергәнмен. Шунда тегеләр барысы берьюлы башларын күтәреп миңа төбәлде. Һәм мин көтелмәгән хәлдән катып калдым. Арка үзәге буйлап салкын йөгереп узды. Үземне бөтенләй башка дөньяга, бөтән төрле кешеләр арасына эләккәндәй хис иттем. Узды инде бу дулкын бераздан. Тик мин барыбер әйтерлек сүз тапмадым. Кызганыч та булып китте, көләсе дә килде.

Дүртесенең дә авызында лампочка иде.

pinterest.com



«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

ИСКИТМӘЛЕ ОЛЫ БОЛГАЕР

Апас районының Олы Болгаер авылы тарихы бәян ителгән китапның исеме бу. Авторы – якташлары, журналист Хәмзә Бәдретдинов. Әмма бүген сүзебез ул хакта түгел. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты оештырган «Без тарихта эзлебез» бәйгесендә Апас районы данын яклаган Аманулланнар гаиләсе турында.

Коллегабызның йорттан-йортка йөреп Олы Болгаер тарихын җыюы халыкка шактый уңай тәэсир иткән дип уйларга кирәк. «Без генә түгел, тагын бик күпләр шәҗәрәләрен төзи, нәсел тамырларының тарихын барлый башладылар», – ди Алинә Аманулина бу җәһәттән.

Алинә үзе дә, актарына торгач, әби-бабаларының 12 нче буынына кадәр «төшеп» җиткән. Әлегә ул әнисе Рузинә ягыннан әби-бабаларын барлаган. Алга таба әтисе ягына да күчәргә исәбе. Ул гына да түгел, ире Илфат та, кызыксынып китеп, нәсел-нәсәпне белешеп куйсаң, әйбәт булыр иде, дип әйткәли башлаган.

Авылда Аманулланнар кебек тик тора белми торган гаиләләр булу хәерлегәдер ул. Башкаларны да үз артыңнан ияртүчеләр кирәк бит.

– Мин бәләкәй чактан ук бик актив идем, – ди Алинә. – Сәхнәдән дә төшеп тормадым. Хәзер дә җырларга бик яратам. Әле күптән түгел генә районда булып узган Әлфия апа Авзалова фестивалендә дә икенче турга үткән идем. Мәшәкатьләр чыгып, чыгышымны дәвам итәргә мөмкинлек булмады. Бәйгегә дә аерым атап әзерләнүебез түгел иде. Эш шунда: авылда без беренчеләрдән булып гаилә бәйрәме үткәрдек. Дөресрәге, шәҗәрә төзелеп беткәч, үзебезчә шундый зур эш эшләдек бит инде, ничектер билгеләп үтәсе килде. Соңрак районнан шалтыратып: «Сезнең бәйрәм безгә бик ошады. «Без тарихта эзлебез» дип аталган бәйгенең зона ярышында катнаша алмассызмы икән?» – дигән үтенеч белән чыктылар. Ризалаштык. Барысы да әзер кебек тоелган иде. Тик алай ук булып чыкмады, ныклап әзерләнергә туры килде. Район җитәкчеләре дә ярдәм итте. Зур рәхмәт аларга.

Анысы шулай инде: бәйрәм – бәйрәм белән, бәйге шактый җаваплылык өсти бит.

– Яшел Үзәнгә 14әү бардык, – ди Алинә. – Әниебез Рузинә башлап йөрде.

ШӘҖӘРӘ
«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

Без гаиләдә өч кыз үстек. Барыбыз да катнаштык. Әнинең энесе Рамил Зарифуллин гармунда уйнады. Балалар, оныклар – берсе дә читтә калмады. Кул эшләреннән күргәзмә оештырдык. Аларның күбесен әни үз куллары белән эшләгән: чиккән, теккән, ясаган. Әтием Гаделҗан гомер буе тракторчы булып эшләде, әнием – терлекчелектә. Мактаулы хезмәтләре өчен күп кенә бүләкләре дә бар. Аларның да кирәге чыкты. Жюри әгъзалары бик кызыксынып карады. Аннан театральләшкән чыгыш әзерләдек. Сәхнәгә зур шәҗәрә агачы ясап куйдык та, әниләр-әтиләр аңа ботаклар куйдылар, балалар шул ботакларга алмалар элделәр. Татар халык ашлары дип өстәлгә куелган сый-нигъмәтләрнең барысын да үзебез әзерләдек. Түгәрәк ипигә кадәр пешереп бардым. Өчпочмак, коймак, пәрәмәчләребез дә бик тәмле булды, авыл каймагы да алып барган идек, катык та оеттык. Өстәлдәге савыт-сабаларга да милли рәсемнәр төшерелгән иде.

Ризыкларның тәмле булуына гаҗәпләнәсе дә юк инде. Алинә кайчандыр бухгалтер белгечлеге алса да, декретта утырганда заманалар үзгәреп китеп, кыскартылуга эләккән. Аннан чыккач, озак сайланып тормаган, ашханәгә пешекче булып урнашкан.

Бәйрәмнәр, бәйгеләр үткәч, Алинә шәҗәрәне дә, җыелган документларны да, саклар өчен, әнисе туып үскән, хәзер әнисенең энесе Рамил Зарифуллин яшәгән төп нигезгә китереп куйган. «Шулай дөресрәк дип саныйм, – ди ул. – Туганнар да күбрәк шунда җыела, әби-бабалар рухы да шунда саклана бит». Өстәвенә алар бергәләп нәсел-нәсәпнең тамырларында казынуны тагын да дәвам итәргә, архивларда утырырга да уйлыйлар. Хәзер

инде балалары ярдәм итәр. Уллары Илфар өйләнгән, әти-әнисен оныклар белән сөендергән. Илсинә дизайнер булырга җыена, Казанда көллияттә белем ала. Зәринә икенче сыйныфта укый. Ул да әнисе кебек җырларга ярата: бу арада «Йолдызлык» фестивалендә катнашырга әзерләнеп йөри.

– Бәйгедә дә бик теләп катнаштылар. Шуңа күрә балаларым тукталып калмаслар, – дип, зур өмет баглый әниләре.

Сүз башымны искитмәле Олы Болгаер дип башлавым да юктан гына түгел иде.

– Авыл клубында чаралар үткәрелеп тора, – ди Алинә. – Әле күптән түгел генә Әнсар Галиев үз урамнарына багышланган китапны халыкка тәкъдим итте. Ул да, Хәмзә абый кебек, йорт саен йөреп, кешеләр белән очрашып, балачакта уйнаган уеннарга кадәр тәфсилләп-тәфсилләп язган. Күп кеше кайткан иде. Бик зур бәйрәм булды. Монысын инде сер итеп кенә әйтәм: әтиемнең сеңлесе дә гаилә бәйрәме үткәрергә әзерләнеп йөри әле.

Аманулланнарның да хыяллары юк түгел. Ике яктан да әби-бабайларны, туганнарны барлап, фотолар җыеп, бер кечкенә генә китап чыгарсаң да ярар иде, дип уйлый Алинә. Монысы инде бигрәк тә балаларга, оныкларга истәлек өчен әйбәт булыр иде.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Язмыш

БӘХЕТ ТӨЕНЧЕГЕМ

Бөгелмәдә яшәүче 88 яшьлек Тәслимә Мәһдиева, яратып, иренә әнә шулай дип дәшкән. Бәхетле никахта 29 ел бергә яши алар. Парлы гомерләре күпләргә үрнәк була. Гамбәр абый сөйгәненә авыр сүз әйтү түгел, хәтта бер чиләк су да күтәртми. Еллар узгач, үзен авыру аяктан еккач, Тәслимә апа ирен кадерләп яшәтә.

– Без сугыштан соңгы авыр елларга эләктек. Акча юк, ничек тә яшәргә кирәк. Мәктәпне бетергәч, газ счетчикларын тикшерүче булып эшкә урнаштым. Бервакыт утларны тикшереп йөргәндә, мине булачак килендәшләрем күреп калган. Алар ирләренең энеләренә минем хакта әйткән. Шуннан соң Гамбәр мине эзләп тапты. Бер-беребезне ошаттык без. Бәхетебезне түгәрәкләп, башта улым Равил, аннары Наил туды, – дип искә ала Тәслимә апа. – Гамбәр мине бик хөрмәт итеп яшәде. Ир-атлардагы барлык яхшы сыйфатларга ия иде ул. Бакчабызда бер генә эшне дә эшләтмәде. «Синең эшең өйдә», – дип кенә әйтә иде.

Тәслимә апа ире турында бик яратып, озак итеп сөйли. Бергә яшәгән чакларын сагына ул. 29 ел бергә яшәүнең 13 елын ире урында гына ятса да, газизен бик юксына Тәслимә апа. Бай булмадык, рәхәт яшәдек, ди ул.

– Ул чакта тормыш җиңел булмады. Ирем белән өйләнешкәндә аның урта мәктәп белеме юк иде. Кече улым тугач, ул кичке мәктәпкә укырга керде. Аннан соң югары белем алды. Тормышыбыз түгәрәкләнгән кебек иде. Эше дә бар, акчасын да яхшы түли башладылар. Тик язмышның планнары башка булган икән. Гамбәр абыең авырып китте. Аның аркасында шеш барлыгын әйттеләр. Ул урынга калды. Ярдәм итмәсме дип, катлаулы операция дә ясадылар. Тик булмады. Шул операциядән соң иремнең ике ел куллары тотмады. Мин ул чакта бухгалтер булып эшли идем. Эшемне ташларга туры килде. Иремне бер дә авырсынмыйча, кадерләп карадым, – дип сөйли Тәслимә апа.

Мәндиевләрнең гаилә архивыннан

Язмыш аларны аерганда Гамбәр абыйга – 64, Тәслимә апага 59 яшь була. Ирен җирләгәч, ул яңадан эшкә урнаша. Пенсиягә чыгар өчен җитмәгән хезмәт елларын әнә шулай тутыра.

Тәслимә апа уллары һәм аларның гаиләләре хакында яратып сөйли. Алар улларын кечкенәдән эшләтеп үстерәләр. 6 нчы сыйныфта укыганда, берсен – он тарту заводына, икенчесен йөкче итеп эшкә урнаштыралар. Егетләр эштән курыкмый. Әти-әнисенә ярдәмче булалар. Шөкер, хәзер дә әниләре өчен өзелеп торалар икән.

– Олы улым Равил гаиләсе белән Бөгелмәдә яши. Наилемне беләсездер инде. Әтисенең 30 яше көнне тапкан идем мин аны. Шул вакыттан 63 ел узып та киткән. Наил гомер буе җитәкче урыннарда эшләде. Чаллыга мэр итеп куйгач та, ничекләр эшләр инде балам, дигән идем. Зур шәһәрне җитәкләү җиңел эш түгел бит. Аны билгеләгәч, шунда барып, шәһәрне карадым. Аллаһы Тәгаләдән балама ярдәм итүен сорадым, – ди Тәслимә апа. – Шунда бер вакыйга исемә төште. Бервакыт мин эшкә барам. Алдымда шәһәр җитәкчебезнең әнисе атлый. Артыннан барганда, вәт бәхетле ана, улың шәһәр белән идарә итсен әле, дим. Күңелдәге теләкнең еллар узгач кабул булганын белми дә калдым. Шуңа да мин һәрвакыт изге теләктә.

Тәслимә апа киленнәре турында бик яратып сөйли. Икесен дә үз итә. Ни генә булса да, килен яклы ул. Ике улын да кечкенәдән ашарга пешерергә, өй җыештырырга өйрәтә ул. Туйда исә: «Улларым ашарга пешерә белә. Хатын-кыз эше дип тору юк. Кайсыгыз алдан кайта, шул ашарга әзерли», – дип әйтеп сала. Улларына, яхшы булыгыз, гаиләгезне саклагыз, хатыннарыгызны кадерләгез, дип киңәш бирә. Ә уллары исә әтиләрен искә аладыр, мөгаен. Әниләренә булган мөнәсәбәтен күреп үскән бит алар. Әнә шуңа да үзләре дә әниләренең дә, гаиләләренең дә кадерен беләләр.

– Наилемнең исеме Аллаһы Тәгалә бүләге дигәнне аңлата. Дөрес, һәр бала бүләк инде ул. Әмма минем Наилем бик ярдәмчел, кешелекле, миһербанлы, сүземне тыңлаучан булды. Эше катлаулы булса да, яныма кайтырга вакыт таба. Аны да кызганам. Кайтып китәренә 4 сәгать кирәк. Янымда берәр сәгать кенә торса да, күпме вакытын әрәм итә, дим. Ә күрешәсе килә. Бик сагынам. Әле менә әллә кышка Чаллыга күченеп торасы инде дим. Янәшәсендәрәк буласым килә, – ди Тәслимә апа. – Тормышта авыр чаклар күп булды. Әтиләре урында ятканда, улларым ярдәм итте. Аеруча Наилем килеп җитәр иде. Дәүләт эшендә эшләсә дә, төннәрен килеп булышты. Без авырлыклар күреп, тормышта чыныгып яшәдек. Шуңа да кеше кайгысына битараф түгелбез.

Тәслимә апа биш вакыт намазын калдырмый. Гел догада.

– Иремнең авырып китүе безне тагын да берләштерде. Мин аны бик яратып яшәдем. Чын мәхәббәт шулдыр, – ди Тәслимә апа. – Аллага шөкер, мин бүген дә бик бәхетле. Исән-саумын, һәр туган көнгә сөенәм. Дога кыла алам. Бәлки кайчак дөрес тә яшәмәгәнмендер, дөрес тә эшләмәгәнмендер. Сынаулар тикмәгә булмаган. Тик шулай да мин язмышыма бик рәхмәтле. Яшәү мәгънәсен, ямен тоям. Башкаларга да шуны телим. Бер-берегезне аңлап, санлап, кадерләп яшәсәгез иде. Гомер тиз уза ул. Сизми дә каласың…

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6715 данә
Гомуми тираж – 15318 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 350

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+